ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.01. 2022 Олы Кайбыч ав. № 12

Хезмәт хакы Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган Кайбыч муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын күтәрү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт хакы исәпләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 30 октябрендәге 1029 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләре өчен Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентларын һәм тариф ставкаларын (окладларын) билгеләргә (кушымта).

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт хакы исәпләнә торган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2017 елның 29 декабрендәге 522 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) вакыттан үз көченә керә һәм 2022 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда бастырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Н.Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның
«18» 01 №12
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары)

| Бердәм тариф челтәре түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкалары (окладлары), сум |
|---|---|---|
| 1 | 1,0000 | 13 617,0 |
| 2 | 1,0178 | 13 860,0 |
| 3 | 1,0362 | 14 110,0 |
| 4 | 1,0538 | 14 350,0 |
| 5 | 1,0736 | 14 620,0 |
| 6 | 1,0927 | 14 880,0 |
| 7 | 1,1133 | 15 160,0 |
| 8 | 1,1331 | 15 430,0 |
| 9 | 1,1530 | 15 700,0 |
| 10 | 1,1743 | 15 990,0 |
| 11 | 1,1948 | 16 270,0 |
| 12 | 1,2168 | 16 570,0 |
| 13 | 1,2389 | 16 870,0 |
| 14 | 1,2609 | 17 170,0 |
| 15 | 1,2837 | 17 480,0 |
| 16 | 1,3072 | 17 800,0 |
| 17 | 1,3307 | 18 120,0 |
| 18 | 1,3549 | 18 450,0 |

Искәрмә. Җитәкче урынбасарының тариф ставкасы (оклады) күләме тиешле җитәкченең тариф ставкасыннан (окладыннан) 1-2 разрядка түбәнрәк билгеләнә.